МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

10 гыйнвар 2022 ел

**КАРАР**

№ 11 02

Шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәрендә наркотикларга каршы комиссия турында» 2008 елның 11 мартындагы 82 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 23 ноябрендәге 733 номерлы Указы белән расланган 2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең наркотикларга каршы дәүләт стратегиясе, Татарстан Республикасының «Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында» 2009 елның 29 октябрендәге 50-ТРЗ номерлы Законының 22 статьясы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында балалар сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары, шәһәр Уставының 53 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәрендә наркотикларга каршы комиссия турында» 2008 елның 11 мартындагы 82 номерлы карарына, 1 нче кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Шәһәр Хакиме — Н.Г. Мәһдиев

Яр Чаллы шәһәре Хакименең
2022 елның 10 гыйнварындагы
М 02 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре Хакименең
2008 елның 11 мартындагы
82 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә
наркотикларга каршы комиссия турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә наркотикларга каршы комиссия (алга таба – комиссия) җирле үзидарә башкарма хакимияте органнарының наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең һәм аларның прекурсорларының законсыз әйләнешенә каршы тору эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итә торган орган булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль хокукый актларга, Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия карарларына һәм әлеге нигезләмәгә таяна.

3. Комиссия үз эшчәнлеген дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар белән үзара бәйләнештә гамәлгә ашыра.

4. Комиссиянең төп функцияләре булып тора:

1) наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең һәм аларның прекурсорларының законсыз әйләнешенә каршы торуга, шул исәптән әлеге әйләнешне профилактикалауга, шулай ук бу өлкәдә шәһәр максатчан программаларын тормышка ашыру нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар эшләү;

2) наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең һәм аларның прекурсорларының законсыз әйләнешенә каршы тору өлкәсендә закон һәм башка норматив хокукый актларны камилләштерү буенча билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр әзерләү һәм кертү, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының эш органнарына комиссия эшчәнлеге турында еллык докладлар бирү;

3) башкарма хакимиятнең территориаль органнары эшчәнлеген координацияләү, шулай ук аларның җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлеге;

4) наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең һәм аларның прекурсорларының законсыз әйләнешенә каршы тору өлкәсендә Россия Федерациясенең башка субъектлары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән хезмәттәшлек итү;

5) наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары турында Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарында каралган башка мәсьәләләрне хәл итү.

5. Үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен комиссия хокуклы:

1) үз компетенциясе кысаларында наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең һәм аларның прекурсорларының законсыз әйләнешенә каршы тору эшчәнлеген

оештыруга, координацияләүгә һәм камилләштерүгә кагылышлы карарлар (рекомендацияләр) кабул итәргә, шулай ук әлеге карарларның (рекомендацияләрнең) үтәлешенә контрольне гамәлгә ашырырга;

2) дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый һәм башка оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан аның эшчәнлеге өчен кирәкле документлар, материаллар һәм мәгълүмат сорарга һәм алырга;

3) комиссия функцияләре нигезендә, үз утырышларында комиссия әгъзаларын һәм башка затларны тыңларга.

6. Комиссия үз эшчәнлеген планлы нигездә башкара.

7. Комиссия составы шәһәр Хакиме карары белән раслана.

## 2 бүлек. Комиссия рәисенең һәм әгъзаларының вәкаләтләре

8. Комиссия рәисе булып Яр Чаллы шәһәре Хакиме тора (алга таба – комиссия рәисе).

9. Комиссия рәисе аның эшчәнлегенә җитәкчелекне гамәлгә ашыра, комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә, комиссия утырышларын алып бара, комиссия утырышлары беркетмәләрен имзалый, комиссия эшчәнлеге белән бәйле карарлар кабул итә.

10. Комиссия рәисе аның компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча комиссия исеменнән эш алып бара.

11. Комиссия рәисе урынбасары, ул булмаганда, комиссия утырышларын алып бара һәм утырышлар беркетмәсен имзалый, үз компетенциясе чикләрендә йөкләмәләр бирә һәм комиссия рәисенең аерым күрсәтмәсе нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

12. Комиссиянең җаваплы секретаре:

1) комиссиянең эш планы проектын эшли;

2) комиссия утырышларын әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итә;

3) комиссия карарларының (рекомендацияләренең) үтәлешенә контрольне тәэмин итә;

4) наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең һәм прекурсорларның законсыз әйләнешенә каршы тору өлкәсендә наркоситуациягә мониторинг үткәрә;

5) Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия белән хезмәттәшлекне тәэмин итә;

6) комиссиянең эш башкаруын оештыруны һәм алып баруны гамәлгә ашыра.

13. Утырышта карап тикшерелә торган мәсьәләләрне әзерләгәндә һәм фикер алышканда комиссия әгъзалары тигез хокукларга ия. Комиссия утырышында аның әгъзаларының булуы мәҗбүри.

Комиссия әгъзасы утырышта була алмаса, ул комиссия секретаренә алдан хәбәр итәргә тиеш.

Комиссия әгъзасы булып торган вазыйфаи затның вазыйфаларын башкаручы зат комиссия утырышында киңәш бирү тавышы хокукы белән катнаша.

Аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, комиссия утырышы тулы хокуклы санала.

Карап тикшерелә торган мәсьәләләргә бәйле рәвештә, комиссия утырышларында катнашуга башка затлар да җәлеп ителә ала.

14. Комиссия әгъзалары хокуклы:

1) комиссия эшчәнлегенә турыдан-туры кагылышлы документлар һәм материаллар белән танышырга;

2) комиссия утырышларында чыгыш ясарга, комиссия компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертергә һәм, кирәк булган очракта, әлеге мәсьәләләр буенча тавыш бирүне үткәрүне таләп итәргә;

3) комиссия утырышларында тавыш бирергә;

4) билгеләнгән тәртиптә, комиссия рәисе белән килештереп, оешма хезмәткәрләрен һәм белгечләрен комиссия эшчәнлеге белән бәйле эксперт, аналитик һәм башка эшкә җәлеп итәргә;

5) комиссия карары белән килешмәгән очракта, язма рәвештә комиссия беркетмәсендә чагылдырылырга тиешле аерым фикер белдерергә.

15. Комиссия әгъзалары бурычлы:

1) комиссия, комиссия рәисе карарлары нигезендә яки комиссия әгъзаларының беркетмә карары белән расланган тәкъдимнәре буенча комиссия каравына чыгарыла торган мәсьәләләрне әзерләүне оештырырга;

2) комиссия утырышларында катнашырга;

3) үз вазыйфаи вәкаләтләре кысаларында комиссия карарларын үтәүне оештырырга;

4) комиссия эшен оештыру кагыйдәләрен билгели торган норматив хокукый актлар таләпләрен үтәргә.

## 3 бүлек. Комиссия эшен планлаштыру һәм оештыру

16. Комиссия утырышлары план нигезендә үткәрелә. План комиссия рәисе тарафыннан раслана һәм бер елга төзелә.

17. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Кирәк булган очракта, комиссия рәисе карары буенча комиссиянең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

18. Комиссия утырышлары планы, һәр мәсьәлә буенча аны карап тикшерү срогы һәм мәсьәләне әзерләү өчен җаваплылар күрсәтелгән, комиссия утырышларында карап тикшерелергә тиешле төп мәсьәләләр исемлеген үз эченә ала. Комиссиянең күчмә утырышлары үткәрелгән очракта, утырышларны үткәрү урыны күрсәтелә.

19. Комиссия утырышлары планына тәкъдимнәр планлаштырылган чор башланганчы кимендә бер ай алдан яисә комиссия рәисе тарафыннан билгеләнгән срокларда язма рәвештә кертелә. Тәкъдимнәр үз эченә алырга тиеш:

1) мәсьәләнең исеме һәм аны комиссия утырышында карап тикшерү кирәклеген кыскача нигезләү;

2) тәкъдим ителә торган карар формасы;

3) мәсьәләне әзерләү өчен җаваплы орган исеме;

4) комиссия утырышында карап тикшерү срогы һәм кирәк булганда, комиссия утырышын үткәрү урыны.

Хәл итү орган компетенциясенә керми торган мәсьәлә план проектына тәкъдим ителгән очракта, инициаторга карап тикшерү күздә тотыла торган мәсьәлә аның компетенциясе чикләренә кергән орган белән тәкъдимне килештерү процедурасын үткәрергә кирәк.

20. Кергән тәкъдимнәр нигезендә чираттагы чорга комиссия утырышлары планы проекты төзелә, ул комиссия рәисе белән килештереп, агымдагы елда комиссиянең соңгы утырышында фикер алышу һәм раслау өчен чыгарыла.

21. Комиссия утырышларының расланган планы күчермәләре комиссия әгъзаларына җибәрелә.

22. Комиссия утырышларында өстәмә (планнан тыш) мәсьәләләрне карап тикшерү комиссия рәисе карары буенча гамәлгә ашырыла.

## 4 бүлек. Комиссия утырышларын әзерләү тәртибе

23. Комиссия утырышларында карап тикшерү өчен тиешле материалларны әзерләү йөкләнгән комиссия әгъзалары, комиссия утырышларының расланган планы нигезендә,

әлеге утырышларны әзерләүдә катнашалар һәм материалларның сыйфаты һәм үз вакытында тапшырылуы өчен шәхси җаваплылык тоталар.

24. Комиссия утырышының көн тәртибе проекты чираттагы утырышка әзерлек процессында ачыклана һәм раслау өчен комиссия рәисенә тапшырыла.

25. Утырыш үткәрү датасына кадәр кимендә 30 көн алдан комиссиягә түбәндәге материаллар тапшырыла:

1) карала торган мәсьәлә буенча аналитик белешмә;

2) карап тикшерелә торган мәсьәлә буенча, карарлар (йөкләмәләр) пунктларын башкаручылар һәм үтәү сроклары күрсәтелгән карар проекты;

3) төп докладка иллюстрацион материаллар, әгәр алар булса.

26. Комиссия утырышларында карап тикшерү өчен материалларның үз вакытында әзерләнүенә һәм тапшырылуына контроль комиссиянең җаваплы секретаре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

27. Материаллар комиссия тарафыннан билгеләнгән срокта тапшырылмаган яки әлеге Нигезләмәне бозып тапшырылган очракта, комиссия рәисе карары буенча, мәсьәлә карап тикшерүдән алынырга яисә карап тикшерү өчен, башка утырышка күчерелергә мөмкин.

28. Җаваплы секретарь  комиссия әгъзаларына һәм утырышка чакырылган затларга комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында  үткәрү датасына кадәр кимендә 2 көн алдан өстәмә рәвештә хәбәр итә.

29. Комиссия утырышына чакырылган вазыйфаи затларның составы, карап тикшерелә торган мәсьәләләрне әзерләү өчен җаваплы комиссия әгъзаларының тәкъдимнәре нигезендә, комиссиянең җаваплы секретаре тарафыннан төзелә һәм комиссия рәисенә алдан ук җиткерелә.

## 5 бүлек. Комиссия утырышларын үткәрү тәртибе

30. Комиссия утырышлары комиссия рәисе яисә аның йөкләмәсе буенча комиссия рәисе урынбасары тарафыннан чакырыла.

31. Комиссия утырышларында катнашучы затлар комиссиянең җаваплы секретаре тарафыннан теркәлә.

32. Әгәр анда комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, аның утырышы тулы хокуклы санала.

33. Утырышлар комиссия рәисе рәислегендә үтә, ул түбәндәгеләрне башкара:

1) комиссия утырышларын алып бара;

2) комиссия утырышының көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча фикер алышуны оештыра;

3) комиссия әгъзалары тарафыннан күрсәтелгән кимчелекләр һәм карар проекты буенча тәкъдимнәр буенча фикер алышуны оештыра;

4) кергән заявкаларның чираты тәртибендә, комиссия әгъзаларына, шулай ук чакырылган затларга чыгыш ясау өчен сүз бирә;

5) тавыш бирүне һәм тавышларны санауны оештыра, тавыш бирү нәтиҗәләрен игълан итә;

6) әлеге Нигезләмә нигезләмәләре үтәлешен тәэмин итә.

34. Көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча утырышта доклад белән, комиссия әгъзалары яисә комиссия рәисе белән килештереп, комиссия әгъзалары тарафыннан вәкаләтләнгән затлар чыгыш ясый.

35. Комиссия утырышы регламенты утырышка әзерлек вакытында билгеләнә, ә раслана – турыдан-туры утырышта .

36. Тавыш биргәндә комиссия әгъзасы бер тавышка ия һәм шәхсән үзе тавыш бирә. Комиссия тарафыннан кабул ителгән карар белән килешмәгән комиссия әгъзасы, әлеге карар кабул ителгән комиссия утырышында тавыш биргәннән соң, беркетмәгә кертелә

торган фикерне комиссия әгъзаларына җиткерергә хокуклы. Язма рәвештә бәян ителгән аерым фикер комиссия утырышы беркетмәсенә теркәлә.

37. Комиссия карарлары, ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы буенча кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

38. Рәислек итүче тарафыннан игълан ителгән тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмәгә кертелә. Комиссиянең ябык утырышларын үткәргәндә (аерым мәсьәләләр буенча ябык фикер алышу) материаллар әзерләү, утырышка кертү, беркетмәләр һәм кабул ителә торган карарларны рәсмиләштерү сер булган документлар белән эшләүнең билгеләнгән кагыйдәләрен һәм сер режимын үтәп гамәлгә ашырыла.

39. Массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең катнашуы һәм кино-, видео-, фотога төшерү, шулай ук комиссия утырышларында тавыш яздыру рәис яисә аның йөкләмәсе буенча комиссиянең җаваплы секретаре тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә оештырыла.

40. Докладчының, өстәмә докладчыларның һәм чыгыш ясаучыларның чыгышларына ярдәмче иллюстрацион материалларны күрсәтү комиссия рәисе рөхсәте белән җаваплы секретарь тарафыннан гамәлгә ашырыла.

### 6 бүлек. Комиссия утырышында кабул ителгән карарларны рәсмиләштерү

41. Комиссия карары, утырыш үткәрү датасыннан соң җиде көн срокта җаваплы секретарь тарафыннан әзерләнә һәм комиссия рәисе тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

42. Беркетмәдә күрсәтелә:

1) рәислек итүченең, утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының һәм чакырылган затларның Ф.И.А.и.;

2) утырыш барышында карап тикшерелгән мәсьәләләр;

3) кабул ителгән карарлар.

Әгәр андыйлар булса, беркетмәгә комиссия әгъзаларының аерым фикерләре теркәлә.

43. Комиссия утырышында карап тикшерелгән һәм алар буенча тәкъдимнәр һәм кимчелекләр әйтелгән материалларны эшләп бетерергә кирәк булган очракта, беркетмәдә комиссия әгъзалары тарафыннан тиешле йөкләмә чагылдырыла. Әгәр эшләп бетерү вакыты махсус әйтелмәсә, эшләп бетерү 10 көнгә кадәр срокта гамәлгә ашырыла.

44. Утырыш беркетмәләре (утырыш беркетмәләреннән өземтәләр), комиссиянең җаваплы секретаре имзаланган беркетмәне алганнан соң өч көн срокта, комиссиянең җаваплы секретаре тарафыннан комиссия әгъзаларына, шулай ук комиссия рәисе тарафыннан расланган исемлек буенча оешмаларга һәм вазыйфаи затларга җибәрелә.

### 7 бүлек. Комиссия карарларындагы йөкләмәләрнең үтәлешен контрольдә тоту

45. Комиссия утырышлары беркетмәләрендәге карарларның һәм йөкләмәләрнең үтәлешен контрольдә тотуны җаваплы секретарь гамәлгә ашыра.

46. Комиссия рәисе аңа контроль нәтиҗәләрен тапшыру срокларын һәм ешлыгын билгели.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары




И.А. Сәгыйдуллина